РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» июля 2026 ел г. Альметьевск № 1257

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә велосипедларны, индивидуаль мобиль чараларын, төрле спорт инвентарын туктату һәм (яки) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яки) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген раслау турында» 2022 елның 23 маендагы 974 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе карарын үтәү йөзеннән

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә велосипедларны, индивидуаль мобиль чараларын, төрле спорт инвентарын туктату һәм (яки) саклау өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яки) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру урыннары һәм схемалары исемлеген раслау турында» 2022 елның 23 маендагы 974 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 апрелендәге 968 номерлы, 2023 елның 15 маендагы 1371 номерлы, 2024 елның 22 апрелендәге 1561 номерлы, 2025 елның 7 августындагы 1896 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

«2.2. Әлмәт шәһәре территориясендә индивидуаль мобиль чараларының хәрәкәт тизлеге чикләнгән урыннар исемлеген расларга (4 нче кушымта) »;

карарга түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

заказ № 4553-940

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И. А. Габдуллинга йөкләргә.

Район
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.А. Ямалетдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Р06-12061/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1644035822
КПП 164401001
ОГРН 1051605067172

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«16» июль 2026 ел №1257
карары белән расланган
4 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә индивидуаль мобиль чараларының хәрәкәт тизлеге чикләнгән урыннар исемлеге

- Ленин урамы (Риза Фәхретдин урамыннан Мәрҗани урамына кадәр) - 15 км/сәг;
- Буалар каскады – 15 км/сәг;
- Шәһәр сусаклагычы - 15 км / сәг;
- Шәһәр күле - 15 км /сәг;
- Риза Фәхретдин урамындагы Бульвар – 15 км/сәг;
- «Яшьлек» паркы-10 км/сәг;
- Скейт – парк (Белоглазов урамы) - 5 км /сәг.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе урынбасары И.А. Габдуллин